Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Иж-Бубый авыл җирлегенең Иж-Бубый торак пунктында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 елның 8 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлегенең Иж-Бубый авылында гражданнар җыены **карар бирде**:

1. Иж-Бубый авыл җирлеге Иж-Бубый авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекtән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Иж-Бубый авылында суүткәргеч челтәрләргә хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, тирән насосларны ремонтлау
- Иж-Бубый авылының Татарстан урамы буенча юлларга вак таш җәю һәм ремонтлау
- Иж-Бубый авылы урамнарын кардан чистарту
- Тракторны ремонтлау һәм карап тоту.
- Иж-Бубый авылында агач кисү

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иж-Бубый авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Р.Р. ВАҺАПОВ

Совет Иж-Бобьинского сельского поселения
Иж-Бубый авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002460